ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 472-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 472-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2114-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (2020 елның 25 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге эчтәлектәге 3 өлешне өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Шәхси эшкуарның әлеге статьяга ярашлы рәвештә билгеләнгән салым салуның патент системасы кулланылган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча еллык керем алу мөмкинлеге күләме тиешле календарь елга билгеләнгән коэффициент-дефляторга ел саен индексацияләнергә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектларына индивидуаль эшкуар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча еллык керем алуга потенциаль мөмкин булган, аларга мөнәсәбәттә патент салым системасы кулланылган күләмнәрне тиешле календарь елга билгеләнгән коэффициент-дефляторга ел саен индексацияләү хокукы бирелде.

Россия Федерациясе Салым кодексының 11 статьясы нигезендә коэффициент-дефлятор ел саен, алдагы календарь елда Россия Федерациясендә товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) куллану бәяләренең үзгәрүен исәпкә алып, киләсе һәр календарь елга билгеләнә. Коэффициент-дефлятор социаль-икътисади үсешне анализлау һәм фаразлау өлкәсендә норматив-хокукый көйләү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан дәүләт статистика хисабы мәгълүматларына ярашлы рәвештә билгеләнә һәм коэффициент-дефлятор билгеләнгән елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

Закон проекты югарыда күрсәтелгән хокукны гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән һәм җирле бюджетларга салым салуның патент системасы буенча салым керемнәре дәрәҗәсен саклауга һәм мөмкин кадәр арттыруга юнәлдерелгән.

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Ревспубликасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирүне таләп итмәячәк һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан төшеп калучы керемнәргә китермәячәк. Коэффициент - дефляторны куллану салым базасын арттырырга һәм шуның белән бергә салымның патент системасы буенча җирле бюджетка керүен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Коэффициент-дефляторны куллану бәяләре индексы - 104 процент дәрәҗәсендә билгеләгәндә, өстәмә салым керемнәре 50 млн.сум тирәсе бәяләнә.